# Марсель Ахметзянов

# ЛЕТОПИСЬ ОДНОГО ЗНАТНОГО РОДА

УДК 929.5/.9
ББК 63.2 : 63.3(2Рос=Тат)
Ә87

**Әхмәтҗанов М. И.**

Меңьеллык татар нәселе: Татар шәҗәрәләре һәм этник тарихыбызга бер караш. — Казан: Мәгариф, 2001. — 63 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1103-X

Китапта Әлмәт һәм аңа күрше булган төбәкләрдә тормыш итүче, тарихларда моннан 900 ел әүвәл искә алынган татарның Кирәйет кабиләләренең безнең замангача яшәп килгән нәселләре тарихы бәян ителә.
Хезмәт күпсанлы татар нәсел шәҗәрәләрен, кабер ташларын, тарихи һәм башка язма чыганакларны өйрәнү нәтиҗәсендә язылды.

**БЗ—10(69)—117—2003/2004**

ISBN 5-7761-1103-X © «Мәгариф» нәшрияты, 2001

## КЕРЕШ

Һәрбер тарихи әсәр җәмгыятьттәге иҗтимагый тенденцияләрнең көзгесе булып тора. Җәмгыятьтә барган прогрессив һәм реакцион идеология күренешләре анда чагылмый калмый. Патша Русиясе шартларында да хәл шулай иде. Русия тарихчылары ул заманнарда урыс патшаларының канлы яулап алу сугышларын хуплаган китаплар яздылар, ә башкаларның, шул исәптән татар халкының вәкилләре язган китапларны да көчле цензура күзәтүеннән уздырып, кискәләп, кыскартып басарга гына рөхсәт иттеләр.

1905 елгы революция Русиягә сәяси һәм матбугат иреге биргәч, татар галимнәре дә тарихыбызны милли позициядән торып язуга беркадәр иркенлек алды.

1917—1937 елларда тарих фәне өлкәсендә бөтен СССРда объектив язу тенденциясе беркадәр сакланса да, 1931 елда тарихчы Михаил Покровский мәктәбен «тәнкыйтьләгәч», андый объектив язулар кысылды, илдә идеологик өстенлек урыс шовинизмы идеологиясе позицияләренә бирелә башлады.

СССР шартларында 1937 елга кадәр татар тарихы буенча язылган хезмәтләрдә, тарихи документлар тупланган җыентыкларда сәяси тенденциозлык шаукымы чикләнгән күләмдә генә хакимлек итте. Әлеге кимчелекләр дә илдә хөкем сөргән вульгар социологизм карашлары белән бәйле булудан килде.

Ул дәверләрдәге галимнәрне аңлап та була. Алар каләме белән чыганаклар базасы мөмкинлек биргән кадәрле кысалар эчендә иҗат ителгән хезмәтләр генә язылды. Шунлыктан аларда зур нәтиҗәләр чыгарылмады, һәм һәрбер авторның сәяси платформасы, белем багажы, кемгә хезмәт итүе язган эшләрендә ачык күренә иде.

Татар укучысы ул тарихларның бер өлешен якын кабул итте, саклады, бер өлешен, тыюлар булмаса да, онытты.

Ләкин инде XX гасырның икенче яртысында, тарих буенча беренчел чыганакларның базасы нык киңәюгә дә карамастан, татарның этник тарихын бозып күрсәтергә тырышу тенденцияләре үсеп китте, хәтта аерым авторларның хезмәтләрендә гакылга сыймаслык дәрәҗәдә артты да. Андый бозуларның юнәлешләре күптөрле булды.

Мәсәлән, татар һәм башка милләт тарихчылары вәкилләре арасында, татарны һәм аның тарихи этнонимын милләт буларак инкяр итеп, *болгар, болгар-татар, мишәр, төмән, типтәр, нагайбәк,*

*себер татары, керәшен* диеп язулар модага кереп китте һ. б.

Гомумән, тарих өлкәсендә саташулар XX гасыр ахырында урыс, башкорт, чуваш, мари, удмурт авторларының хезмәтләрендә дә күренә. Татар арасында мондый саташуларның кимрәк булуына сөенергә кала хәтта.

Татар тарихын тенденциозлык рухында язган җирле авторлардан Альфред Халиков, Мирфатыйх Зәкиев, Әбрар Кәримуллин, Зөфәр Мифтахов һ. б. монографияләрен күрсәтергә мөмкин[1]. Аларның китапларында тау кадәрле ышанычлы һәм бәхәсле фактлар бергә туплап язылган булса да, гадел этник тарих чагылмады, чөнки әлеге авторларның берсе — угро-финнар буенча археолог, икенчесе — тел галиме, өченчесе — китап тарихы белгече, ә дүртенчесе элеккеге КПСС тарихы буенча укытучы булып, профессиональ тарихчы дәрәҗәсенә үрли алмадылар.

Шулай ук бу өлкәдә татарның һәм башкортның тари-хын фальсификацияләп язган Р. Кузеев, Р. Янгузин, Ә. Бейеш, Ф. Нәдершина һ. б. хезмәтләре елдан елга күренә киләләр[2].

Мәскәүдә яшәүче аек кына фикерле тарихчы В. Трепавлов та үзенең Уфада басылган хезмәтләрендә фәнгә хилаф булган, мантыйксыз фикерләр уздыра[3].

Әлбәттә, бу тарихчыларның әсәрләрендәге профессиональ кимчелекләр хакында дәшми калырга да мөмкин булыр иде. Ләкин, аларның хезмәтләрендәге ялгыш фикерләргә таянып, Башкортстан Республикасында һ. б. губерналарда татар халкының хокукларын, телен, мәдәниятен, мәгарифен чикләү сәясәте уздырыла. Башкорт галимнәренең кайберләре, татар халкына каршы, аның тарихын бозып, яла ягып хезмәтләр язалар, алар Татарстанның көнчыгышындагы татарларны да «башкортлар» итеп күрсәтү өчен «тиреләреннән чыгардай булып» тырышалар.

Әлеге тарихчылар, Урал буе татарларын юкка чыгарырга тырышып, аларны — Казаннан килгән «килмешәкләр», ә башкортларны «автохтон халык» димәкчеләр.

Уфа галимнәре урта гасырларда патша хөкүмәтенең крайда уздырылган «бүлгәлә һәм хакимлек ит» дигән сәясәтенә тәнкыйди якын килергә теләмиләр, киресенчә, Русия административ органнары тарафыннан берничә губернага бүленеп, геноцид сәясәтенә дучар ителгән татарларның авыр хәленнән туган нәтиҗәләрне тагын да катлауландырырга ярдәм итәләр.

Социаль терминга этник эчтәлек салу сәбәпле, халыкның аңын бутап татарны башкорт итеп яздырып, соңыннан аларга ясалма башкорт телен көчләп тагып, нинди милләт ясап булыр икән?!

Шушы яссылыктан караганда, әлеге авторларга һәм аларның хезмәтләренә карата ихтыярсыздан сораулар туа:

а) Кемнәр алар борынгы башкортлар?

б) «Башкортстан» дигән ил борынгы заманнарда булганмы?

в) Нугай Урдасы тарихы, аның халкының этник составы нигә тискәре аспекттан гына чыгып языла яки аны күрмәскә тырышалар?

г) Нугай Урдасына кергән татар кабиләләренең бүгенге милләткә бәйләнеше ничек?

Без шушы сорауларга карата үзебезнең фикерләребезне бәян итәргә булдык.

*Автор*

# I бүлек

## КЕМНӘР АЛАР БОРЫНГЫ БАШКОРТЛАР, ҺӘМ АЛАР КАЙЛАРДА ЯШӘГӘН? ИСКЕ ТАРИХИ ЯЗМАЛАРДА САКЛАНГАН ХӘБӘРЛӘР

Куелган сорауга җавап эзләү өчен, бай тарихи язма чыганаклар базасы бар. Алар урта гасырларда сызылган карталарда, гарәп, венгр, поляк, урыс, татар галимнәренең хезмәтләрендә сакланган.

Урта гасырларда эшләнгән карталардан нинди мәгълүматлар алырга мөмкин дигәндә, без, иң беренче чиратта, XI гасырның күренекле төрки филологы Мәхмүд Кашгари һәм XII гасыр гарәп географы Идриси сызган карталарны күз алдында тотабыз. Аларның икесендә дә башкорт кавеменең кайсы географик нокталарда яшәгәнлеге күрсәтелгән.

Иң борынгы карталардан саналган Мәхмүд Кашгари хезмәтендә башкортлар яшәгән җирләр Иртыш елгасы буйларында күрсәтелә. Бу урында хәзер Себер татарлары яши. Аларны күршедәге

казакъ халкы *иштәк* дип атый. Себер татарларының күршеләре булган башкортларны да казакълар иштәк дип йөртәләр. Иртыш буйларында, татарларга күрше булып, угор кавеменең ханты-манси халкы да көн итә. Аларны урыслар әүвәлдә *остяк* дип атаганнар.

Мәхмүд Кашгари картасына карата зур гына комментарийлар матбугатта урыс һәм татар телләрендә игълан ителде[4].

Гарәп географы Идриси тарафыннан 1154 елны сызылган дөнья картасында башкорт кабиләсе урнашкан җирләр Кама елгасының югарыгы агымы ярларында итеп күрсәтелә[5].

Итальян картографлары бертуган Пициганилар тарафыннан 1367 елда эшләнгән картада Каманың башланган урынында *пасхерти* (башкортлар) кабиләсе яшәве күрсәтелә. Шул ук информация 1375 елда сызылган «Каталон атласы»нда да кабатлана[6].

XVI—XVII гасырларда сызылган карталарда (Баттиста Агнезе (1525 ел), Сигизмунд Герберштейн (1556 ел), Антоний Дженкинсон (1565 ел), Гессель Герритс (1613 ел), Адам Олеарий (1647 ел) һ. б.) бүгенге Башкортстан Республикасы җирләрендә татарларның Нугай Урдасы дәүләте булганлыгы күрсәтелә.

Беренче урыс картографларыннан Петр Годунов (1667) һәм Семен Ремезов эшләгән сызымнарда башкорт кабиләсе яшәгән урыннар итеп Урал һәм Агыйдел елгалары башланган регион күрсәтелә. Бу регион бүгенге көндә Чиләбе төбәгенә карый.

Нугайлар С.Ремезов картасында Самара шәһәре тирәләрендә күрсәтеләләр.

Йомгаклап әйткәндә, карталарда башкорт-иштәкләрнең XI гасырда — Себердә, XII гасырда Төньяк Уралда яшәүләрен, XIV йөз тарихи чыганакларында да шул ук регионда калуларын раслаучы фактлар бәхәсләргә урын калдырмаслык итеп теркәлгән.

Искә алынган борынгы карталардагы хәбәрләрне урта гасырларда яшәгән галимнәрнең хезмәтләрендә очраган мәгълүматлар да раслап тора.

Болгар иленә 921—922 елларда килгән гарәп дипломаты Ибн Фадлан язмаларында башкорт кабиләсенең Көньяк Уралда яшәве хакында хәбәрләр бар[7]. Гарәп дипломаты язуынча, башкортлар Җаек суының уң як ярында Самара киңлекләренә кадәрге далаларда очраганнар.

Гәрчә гарәп илчесе башкортларны «төрки» дип атаса да, аларның дини ышанулары төркиләр белән бер дә туры килми. Төрки дип аталуга сәбәп башкортларның күчмә тормыш белән яшәүләреннән чыгып нигезләнгән булса кирәк. Көньяк Уралда Ибн Фадлан күргән башкортларның дине угро-финнар диненең бер тармагы булганга охшый. «Башкорт» дип аталмасалар да, венгрларның кардәшләре булган бер кавемнең 1236 елда Болгар дәүләте территориясендә яшәүләре хакында да тарихи хәбәр сакланган.

Хәлбуки, венгр галимнәре үзләренең көнчыгышта калган ватаннары турында гасырлар дәвамында гел кызыксынып яшәгәннәр. Шулардан берсе — монах Юлиан — 1236 елда Болгар иленең башкаласы Биләргә кадәр килеп җитә. Анда ул венгр телендә аңлаша алган бер хатынны очрата. Әлеге хатын аңа, Биләрдән чыгып төньякка таба ике көн барганнан соң, венгр телендә сөйләшә торган халык янына килеп җитәсен әйтә. Юлиан Биләрдән чыгып ике көн баргач, Идел буенда әлеге «венгр»ларны очрата[8]. Алар мәҗүси диндә булганнар һәм венгр телендә аралашканнар. Юлиан, шул ук вакытта, бу венгрларның татарларның союзниклары булуы хакында яза. Шул ук вакытта Юлианның Ватикан папасына юллаган икенче хатында мәҗүси венгрларның Болгар җиреннән качып Суздальга килүләре хакында да хәбәр бар[9].

Юлианның язганнарына куәт бирә торган, татар телендә эшләнгән «Юрматы шәҗәрәсе» мәгълүматлары кызыклы[10]. Ләкин юрматылар XIV гасыр уртасына татарлашып бетеп, соңыннан Нугай Урдасын төзүчеләрнең берсе булып китәләр. Эш шунда ки, венгрлар Идел-Урал буйларыннан күчеп киткәндә, аларның союзында җиде кабилә саналган. Ул кабиләләр арасында исемнәре *Йено, Җормат, Буләр, Тазлар, Унгар* рәвешендә булганнары да мәгълүм[11].

Идел-Урал буйларында венгрларның калдыклары булу хакында тагын бер хәбәр 1320 елда монах Иоганки тарафыннан язылган[12]. Ул язмада сүз татар-мөселманнар тарафыннан идарә ителә торган *Баскард иле* хәлләре турында бара. Конкрет алганда, бу ил Болгар улусының бер өлкәсе булганга охшый. Баскардта мөселманнар аз, күпчелек халык мәҗүси баскардлар була. Ул илнең идарәчесе янына Себер өлкәсе илчеләре килә. Венгр миссионерлары Себер хакимен христианлык таратырга тырышучы итеп күрсәтәләр.

Иоганки язмасыннан түбәндәге хәбәрләр ачыклана: а) татарлар кул астында Баскард иле дигән өлкә була; б) ул өлкә Себер җирләре белән янәшә урнашкан; в) баскардлар мәҗүси булалар, ләкин аларның идарә үзәгендә христианлык-миссионерлык тарату үзәге дә эшләгән.

Баскард җире белән идарә итүче татар-мөселман анда христиан дине пропагандасы алып баруны тыйган. Иоганки баскардлар белән үзенең туган телендә аңлашканга охшый, югыйсә ул алар арасында христианлык таратырга тырышмас иде.

Урыс елъязмаларында Болгар улусы шәһәрләренең XIV гасырның икенче яртысындагы халкы турында хәбәрләрдә кызыклы детальләр күренә. Мәсәлән, аларның берсендә, урыс кнәзьләренең XIV йөзнең икенче яртысында Болгар, Җүкәтау, Кирмәнчек, Казан шәһәрләренә ясаган һөҗүмнәре вакытында, аларның «бик күп татарларны һәм бисермәннәрне үтердек» дигән мәгълүматы теркәлгән[13].

*Бисермән* атамасы кызыклы гына табышмак кебек тоела. Ни өчен дигәндә, хәзерге Удмуртиянең төньягында бүген дә бисермәннәр дигән кечкенә генә бер этник төркем яши. Аларның теле удмурт теленең көньяк диалектына якын. Тел материалы бисермәннәрнең үткән тарихына ачкыч бирә. Этнографлар аларның милли кием ягыннан чувашлар белән уртаклыгын күрәләр. Удмуртларның көньяк диалектында сөйләшүчеләренең теле шактый дәрәҗәдә татарлашкан. Төньяк удмуртлары исә хәзерге җирләренә шактый соң — XIV гасыр ахырында Каманың югарыгы агымы буйларыннан килгәннәр, алар рухи яктан нык кына урыслашкан саналалар. Моннан тыш кайбер документларда Нократ халкының (бисермәннәрнең) чуваш дип аталып йөртелүе хакында мәгълүмат бар[14].

Без XIV—XVI йөзләрдә урыс документларында бисермән дип аталган этник төркемне Болгар улусы чорларында мөселман диненә кергән һәм татарлаша барган угорлар белән тәңгәлләштерү ягында торабыз.

Угорларның татарлаша бару процессы борынгы шәҗәрә текстларындагы төрки-татар кеше исемнәренең башка телнең фонетик законнарына буйсындырылып бозылуында да күренә. Андый очраклардан исемнәр ясауда кулланылган яңгырау тартыкларның саңгыраулаштырылуын башкача аңлатып булмый. Мәсәлән: Чабынчы (Чабынчы шәҗәрәсе) ® Җабынчы, яки Ябынчы булырга тиеш; Чәнкәй (Бәһлуан ата ш.) ® Җанкай булырга тиеш; Пәйке морза (Кара бик ш.) ® Бәйке булырга тиеш; Пачман хан (Кара бик ш.) ® Бачман булырга тиеш һ. б.

Мондый тел күренешләренең тарихи җирлеге була, һәм аларны тел законнары тудырган үзгәрешләр мисалында гына аңлатырга мөмкин.

XV гасыр поляк тарихчысы Матвей Меховский тарафыннан Идел-Урал буендагы угорлар тарихына карата язылган «Ике Сарматия турында трактат» әсәрендә кызыклы хәбәрләр бар. (Поляк халкының зур галиме Матвей Меховский (1457—1523), ярлы гына гаиләдән чыкса да, тырышлыгы сәбәпле югары белем ала һәм Краков университеты профессоры булып җитешә. Ул медицина һәм тарих буенча хезмәтләр язган. Безнең өчен барыннан да бигрәк аның Көнчыгыш Европа тарихын өйрәнүгә багышланган «Ике Сарматия турында трактат» әсәре мөһим.)

Матвей Меховский, полякларның күршеләре булган венгрлар тарихына керешеп, аларның Урал якларыннан ук күчеп килүләре хакында кызыклы һәм кыйммәтле фикерләр бәян итә.

«Башкорт» этнонимы һәм тарихының венгрлар белән бәйле булуы бездән поляк тарихчысы әсәрен игътибарга алуны сорый.

Матвей Меховский Паннониягә IX гасырда килеп утырган венгрларның *юградлар* дип аталып йөртелүләрен һәм аларның Төньяк Уралдагы Югра иле халкы белән бер нәсел булып, бер үк телдә сөйләшүләрен яза[15]. Аларның телләре арасындагы аерма бик кечкенә була. Венгрлар Юградан киткәч, телләрендә анда кулланылмаган лексик берәмлекләрне үзләренең күршеләре булган славяннардан алганнар.

Матвей Меховский Мәскәү кнәзе Иван III нең 1471—1478 елларда Бөек Новгород республикасына каршы сугышып, җирләрен үзенә алуы хакында яза. Хәбәрдән аңлашылганча, Новгородка әүвәлдә буйсынган Вятка, Корела, Пермь, Чиремис, Баскирд, Югра җирләре андагы кавем-кабиләләре белән Мәскәү кнәзьлегенә кертелә. Яулап алынган халыкларны көчләп чукындырып, аларга епископ Стефанны хуҗа итеп куялар. Җирле угорлар Стефанга буйсынмыйча, аны үтереп ташлыйлар. Иван III гә крайны тагын кан түгеп буйсындырырга туры килә, халкын яңадан чукындыралар.

Урал буйларындагы угор халыкларының мәҗүси диннәре 921— 922 елларда Ибн Фадлан Урал елгасы буенда күргән мәҗүси башкортларныкыннан бер ни белән дә аерылмаган:

Другие вышеупомянутые области коснеют в язычестве и идолопоклонстве, поклоняются солнцу, луне,

звездам, лесным зверям и чему попадается; имеют свои языки и наречия: в Пермьской земле — свое наречие, в земле башкир — свое, в Югре и Кореле также свое.

В этих областях не пашут, не сеют, не имеют ни хлеба, ни денег, питаются лесным зверем, которого у них много, а пьют только воду. Живут они в чаще лесов, в шалашах, сделанных из ветвей[16].

Мәскәү князе Иван III Казанга каршы 1469 елда сугыш ачкач, Казан ханы Ибраһим аңа үзенең бөтен иле-җире белән каршы чыга. Аның иленең өлкәләре арасында:

...со всею землею своею, с Камской, и с Сыплинской, и с Костятцкою и з Беловолжскою и Вотяцкою и з Башкырскою (Башкирской)[17]

кебек җирләр күренә. Бу чыганакта искә алынган *башкыр*ларның кайсы тирәдә урнашуларын XVI гасыр тарихчысы Андрей Курбский үзенең «Сказание о взятии Казани» исемле әсәрендә тагын да конкретлаштырып күрсәтә:

...ибо кроме татар в царстве том пять различных народов: мордва, чуваши, черемисы, вотяки или арцы, пятый — башкиры; те башкиры живут в лесах в верховьях большой реки Камы (ассызык безнеке.— *М. Ә.*), которая впадает в Волгу в двенадцати милях ниже Казани[18].

Борынгы башкортларның этник яктан кемлеге проблемасы югарыда күрсәтелгән тарихи язма чыганакларда шактый ачыклана:

1. Иң борынгы башкортлар Иртыш елгасы тамагында, Җаек (Урал) елгасы югары өлешенең уңъяк ярында, Кама елгасының югарыгы өлешендә урнашкан булганнар.

2. Бу башкортлар барысы да угор телләре диалектларында сөйләшкәннәр. Алар, XVI гасыр башларында татар дәүләтләре кул астына эләгеп, Себер, Казан ханлыкларында һәм Нугай Урдасы составында татарлашып беткәннәр.

Пермь якларындагы угор-башкортлар Казан шивәсен үзләштергәннәр; Чиләбе һәм Урал буендагылар Нугай Урдасы татарлары тел үзенчәлекләрендә татарлашканнар, Себердәге Иртыш буе угорлары нугай-кыпчак сөйләшләрен үзләренә алган.

3. Себер угорлары татарлашсалар да, күршеләре аларны, борынгыча, иштәк дип атауны дәвам иткәннәр.

Көньяк Уралдагы татарлашкан угорларны да күршеләре (аеруча казакълар) иштәкләр дип атаганнар.

Пермь ягындагы угорларны да нугай татарлары иштәкләр дип йөрткәннәр. «Иштәк» кушаматы Нугай Урдасы татарлары һәм казакълар тырышлыгы белән үзатама — этнонимга да әйләнеп китә. Мәсәлән, күренекле татар язучысы Таҗетдин Ялчыгол углы үзенең милләте турында «мин болгарлык иштәкмен» дип белдерә[19] һәм псевдонимы итеп «Таҗетдин бине Ялчыгол әл-Башгыри» яки «Таҗетдин бине Яхшыколый әл-Иштәки» дип таныта.

4. Җирле Болгар дәүләте кул астында калган угорларга «башкорт» исеме Идел-Кама болгарлары тарафыннан тагылган атама була. Венгрлар болгарлар килгәнче үк Урал буйларыннан киткәнгә, алар бу кушамат-этноним белән таныш булмаганнар (ассызык безнеке.— *М. Ә.*). «Башкыр», «башгыр», «башкорт» этник атамасы болгар теле мәдәнияте аркылы мордваларга, урысларга, мөселман дөньясына тарала һәм таныла. Тарихтан мәгълүм булганча, норман-урыс исеме белән атаклы булган Скандинавия юлбасарлары, князьләре Святослав җитәкчелегендә, Идел буендагы Болгар һәм Хазар дәүләте җирләрен тар-мар китерәләр. Болгар мөселманнарының аерым төркемнәре 970 елда, һәлакәттән качып, Билла һәм Боксу исемле ике бертуган җитәкчелегендә Венгриягә күчеп килэләр. Алардан бераз соңрак, Хесен (Хәсән) исемле икенче бер болгар бәге җитәкчелегендә, Венгриягә тагын бер болгар мөселманнары төркеме килә. Венгрлар аларны «биләрләр» дип йөрткәннәр. Венгриядәге болгар мөселманнарын гарәп чыганаклары «башкорт»лар дип атый. Бу «башкорт»лар тарихта XIV гасырга кадәр мәгълүм булып, шул дәвердә венгрлар тарафыннан ассимиляцияләнеп бетә[20].

Идел-Урал буйларында зур мәйданнарга таралып яшәгән Нугай Урдасында «башкорт» этнонимы XIV—XVII йөзләрдә кулланылмаган. Тарихчы Д.М. Исхаков язуынча, нугайлар өчен Урал буйларында үзләреннән һәм иштәкләрдән гайре халык булмаган. Әлеге авторның күзәтүләре буенча, нугайлар «башкорт» атамасын урыслар белән документлар язышу аркылы гына кабул итәләр[21].

5. Хәзерге Башкортстан Республикасы территориясе Бөек Нугай Урдасының төп җирләре булып, анда иштәкләр азчылыкны тәшкил иткәннәр. Нугай Урдасы XVII гасыр урталарында таркалып беткәч, аның буш җирләренә көньяктан һәм төньяктан иштәкләр (башкортлар) кереп урнаша, ә урыс

хөкүмәте үзенең иштәкләренә, калган нугайларга караганда, льготаларны, «башкорт» дип раслап, мул бирә. Нугай Урдасының элекке гражданы булу халыкка льгота бирмәгәч, ул вакыйгалар өлешчә, тарихи хәтер булып, риваятьләрдә һәм язма тарихларда, топонимнарда, шәҗәрәләрдә генә сакланган.

Бүгенге Башкортстан Республикасындагы татар халкының күп өлеше — әүвәлге Нугай Урдасы дәүләтенең гражданнары, һәм алар монда төп «башкорт» дип саналган иштәкләрдән борынгырак. Шунлыктан алар — иштәк-башкортлардан ассимиляцияләп ясалган түгел, ә бәлки, табигый татар кабиләләреннән формалашкан халык. Нугай Урдасындагы татар кабиләләре нәселләрендә сакланган шәҗәрәләрнең «башкорт» дип саналган иштәкләргә бер бәйләнеше дә юк. «Башкортлык» — алар өчен фәкать социаль термин. Социаль терминнар белән эш итсәң, татардан, *башкорт* кына түгел, *солдат, лашман, алпавыт, морза, чемоданный, игенче, тархан, казакъ, чуваш, ясак* һ. б. дистәләгән милли этнонимнар әвәләргә мөмкин.

## ИСКӘРМӘЛӘР

1 *Халиков А.Х.* Происхождение татар Поволжья и Приуралья.— Казань: Татарское книжное издательство, 1978; *Халиков А. Х.* Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария.— Казань: Изд-во «Фэн», 1994; *Зәкиев М. З.* Төрки-татар этногенезы.— Казан: «Фикер» нәшрияты / Мәскәү: «Инсан» нәшрияты, 1998; *Каримуллин А. Г.* Татары, этнос и этноним.— Казань: Татарское книжное издательство, 1988; *Мифтахов З. З, Мухаммадиева Д. Ш.* История Татарстана и татарского народа.— Казань, 1993 һ. б.

2 *Кузеев Р. Г.* Происхождение башкирского народа.— М.: Изд-во «Наука», 1974; *Янгузин Р. Г.* Башкорт кабиләләре тарихыннан.— Өфө: «Китап», 1995; *Бейеш Ә.* Башкорт халкының тарихы һәм азатлык көрәше.— Өфө: «Китап», 1993; *Нәдершина Ф.* Минзәлә үә Бөгөлмәләр йәдкәре // Агыйдел.— 2000.— № 7.— Б. 167—179 һ. б.

3 *Трепавлов В. В.* Ногаи в Башкирии, XV — XVII вв. Княжеские роды ногайского происхождения.— Уфа, 1997.

4 *Әхмәтҗанов М. И.* Без тарихта эзлебез // Идел.— 1996.— № 2.— Б. 54 — 59; *Ахметзянов М. И.* Наш след в веках // Идел.— 1996.— № 3 — 4.— С. 35 — 39.

5 *Әхмәтҗанов М. И.* Әлмәт төбәге җирләренең урта гасырларда сызылган тарихи карталарда чагылышы // Проблемы изучения истории заселения и образования населенных пунктов Альметьевского региона. Выпуск VII.— Казань: РИЦ «Дом печати», 2000.— С. 47.

6 *Әхмәтҗанов М. И.* Каталон атласы // Идел.— 1996.— № 4.— Б. 46 — 47; *Әхмәтҗанов М. И.* Бертуган Пициганилар картасы // Идел.— 1997.— № 7.— Б. 62 — 63; *Әхмәтҗанов М. И.* Әлмәт төбәге җирләре...— Б. 48.

7 *Ковалевский А. П.* Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921—922 гг.— Харьков, 1956.— С. 131.

8 Известия венгерских миссионеров о монголо-татарах и Восточной Европе (XIII в.) // Сборник документов по истории СССР. Часть I. IX—XIII вв.— М.: Изд-во «Высшая школа», 1970.— С. 229.

9 Известия венгерских миссионеров...— С. 234.

10 Шежере башкир племени Юрматы // Башкирские шежере.— Уфа, 1960.— С. 27—35.

11 *Немет Ю. Ф.* Венгерские племенные названия у башкир // Археология и этнография Башкирии. IV.— Уфа, 1971.— С. 252.

12 Письмо Иоганки, содержащее сведения о татарах (1320 г.) // Из глубины столетий.— Казань: Татарское книжное издательство, 2000.— С. 157 — 160.

13 Источники по истории Татарстана (XVI—XVIII вв.).— Казань, 1993.— С. 10.

14 *Исхаков Д. М.* От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV — XVII вв.).— Казань, 1998.— С. 38.

15 *Матвей Меховский.* Трактат о двух Сарматиях.— М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1936.— С. 118.

16 *Матвей Меховский.* Трактат... — С. 117.

17 Источники по истории Татарстана... — С.15.

18 *Курбский Андрей.* Сказание о взятии Казани // Древняя Казань глазами современников и историков.— Казань: Изд-во «Фест», 1996.— С. 136.

19 Шежере башкир племени Айле // Башкирские шежере.— Уфа, 1960.— С. 169.

20 *Хвольсон Д. А.* Известия о хозарах, буртасах, болгарах, мадьярах, славянах и руссах Абу-Али Ахмеда бен Омар Ибн-Даста.— СПб., 1869.— С. 108 — 109.

21 *Исхаков Д. М.* От средневековых татар... — С. 161.

# II бүлек

## НУГАЙ УРДАСЫ ҺӘМ АНЫҢ КАБИЛӘЛӘРЕ СОСТАВЫ

Нугай Урдасының оеша башлавы атаклы Идегәй эшчәнлеге белән бәйле була. Аның 1391 елны Алтын Урда ханы Туктамышка каршы Аксак Тимер белән берлектә сугыш ачуы, Алтын Урда армиясенең җиңелүе Идегәйгә үз кулына власть тупларга мөмкинлек бирә, һәм ул үзенең Мангыт кабиләсендә би буларак ныгый. Идегәй би, мангытларга таянып, Алтын Урда дәүләтендә властьны үз кулына ала һәм анда 1420 елга кадәр идарә итеп килә. Идегәй үтерелгәч, аның урынына уллары күтәрелә, һәм башкаласы Сарайчык булган Нугай Урдасы акрынлап киңәя, көчәя бара.

Нугай Урдасының җирләре көньякта Бохарадан алып төньякта Пермь тирәләренә, көнчыгышта Иртыш буйларыннан көнбатышта Идел буйларына кадәр җәелә. (Соңрак хәтта Дунай буйларына кадәр җитә.)

Бу урдада *нугай* исеме нык кына таралып, урда составындагы төрле татар кабиләләре — *мангытлар, кыпчаклар, каңлылар, кенегесләр, коңгыратлар, кирәйетләр, кыятлар, аргыннар, шириннәр, сөн* яки *шөннәр (өшеннәр), найманнар, катайлар, меңнәр, тамьяннар, юрматылар, боркытлар* һ. б. арасында танылa.

Бу кабиләләрнең күпчелек өлеше Казан ханлыгы халкын формалаштыруда да катнашкан, алар шулай ук Кырым татарлары, үзбәкләр, каракалпаклар, Бүкәй урдасы казакълары, Кавказ нугайларының этник нигезендә дә яталар.

Идел белән Урал арасындагы җирләргә, Нугай Урдасы оешканчы ук, әлеге кабиләләр килеп төпләнгән була, һәм алар, күбесенчә, Болгар улусы башында утырган *бикләр бигенә* буйсынып яшәгәннәр.

Аксак Тимернең 1391, 1395 елгы һөҗүмнәреннән соң, Болгар улусы җимерелә. Болгар, Биләр, Җүкәтау шәһәрләренең халкы чагыштырмача тынычрак булган Агыйдел, Нократ, Чулман, Кәзәнкә, Зөя, Ашыт буйларына күченеп утыра. Бер өлеш халык (мәсәлән, юрматылар) күчмә тормыш белән яши башлый[1].

Без түбәндә Нугай Урдасының зур бер кабиләсен тәшкил иткән кирәйетләр шәҗәрәләре хакында мәгълүмат бирербез.

### КИРӘЙЕТ ШӘҖӘРӘЛӘРЕ

Тарихта кирәйетләрнең килеп чыгышы турындагы хәбәр XII гасырдан килә, ул татарлар тарихын язучы фарсы тарихчысы Фазлулла Рәшид эд-диннең (1247—1318) «Җәмигъ әт-тәварих» китабында бирелә[2].

XVII гасыр Хива дәүләте ханы Әбелгази Баһадир ханның «Тарихе шәҗәрә-и төрек» китабында китерелгән кирәйетләр хакында түбәндәге хәбәр кызыклы.

**Кирәйет иленең зикере**

(искә алынуы.— *М. Ә.*)

Кирәйетнең мәгънәсе «Кара бәрән» димәктер.

Бер кешенең йиде углы бар иде. Йидесе һәм кара тутлы булып, аларны халык *кирәйетләр* диделәр. Анлардан туганларга «Кирәйетләр ыругы» дип әйтдиләр.

Борынгы ил башлары вә маллары күп, падишаһлары башка иде. Ул заманда Кирәйетдән көчле ил юк иде. Йортлары Найманга йакын булдыгыннан, һәмишә Найман илә кяһ сугышып, вә кяһ татулашып торырлар иде.

Кирәйетнең Маргуз исемле бер олуг падишаһсы бар иде, ә аның дәхи Корчакор исемле «Бойрок» ләкабле бер углы бар иде. Корчакорның угланнары күп булды. Беренең исеме Тогорыл иде. Хытай падишаһлары «Уң» дип ләкаб куйдылар. Уңның мәгънәсе «Вилаять падишаһсы» димәкдер. Чыңгыз хан илә орышкан Уң хан шул иде[3].

Уң хан турында XVII гасыр монгол тарихчысы Лубсан Данзанның «Алтан тобчи» тарихында да хәбәрләр китерелә:

Темучин (Чыңгыз хан.— *М. Ә.*) сказал: «Прежде Онг хаган кереитского народа назвался побратимом нашего отца-хагана. Раз он назвался побратимом нашего отца, то и для меня пусть будет он как отец. Так-то! Онг-хагану я буду полезен».

Зная, что Онг-хаган пребывает в темном лесу на Турхуле, Темучин отправился к нему и сказал: «Некогда вы

с нашим отцом назвались побратимами, так будь мне отцом. Жена моя приехала и, сойдя с коня, поднесла шубу из черных соболей».

Онг-хаган очень обрадовался и сказал:
«За твою шубу из черных соболей я оплачу;
Твой отделившийся народ соберу и тебе отдам;
За твою соболью шубу я оплачу;
Твой рассеявшийся народ соберу.
Как почка в пояснице,
Как грудина в груди,—
так это будет!»[4]

Икенче бер хәбәр:

«Чингис стал хаканом» — с таким известием отправил он послами к кереитскому Тогорил-хагану Дахая и Сухэя.

Тогорил-хаган сказал: «Темучин, мой сын, стал хаганом — это правильно. Как можете вы, монголы, жить без хагана?! Не разрушайте же этого согласия. Не лишайтесь же своего единения, откармливайте своего старшего брата». Так говоря, он отправил их обратно[5].

Кирәйет кабиләләре, Чыңгыз империясе төзелгәч аның кул астына кертелеп, күпчелек татарлар кебек, Азия һәм Европа далаларына сибелгәннәр.

Урта Азиядә барлыкка килгән Чыгатай улусында төп кабиләләрдән булган *аргыннар, каңлылар, дулатлар, карлуклар* арасында кирәйетләр дә булганлыгы мәгълүм[6].

Кирәйет кабиләсе вәкилләре Төньяк Кавказдагы нугайлар арасында да билгеле икән. Ул аларда «Кирейт урувы» дип йөртелә[7].

Казакъ халкының Кече Җүз кабиләләре арасында *кереит* кабиләсе иң зур берләшмәләрдән санала[8].

Үзбәкләр һәм каракалпаклар составында да кирәйет кабиләсе барлыгы мәгълүм[9].

Кирәйет кабиләсенең Идел-Урал буйларында кимендә XIII гасырдан бирле яшәгәнлеген дәгъва итәбез. Иң борынгы татар язма чыганагы бу җәһәттән XVII гасырның икенче яртысына карый. Ул чыганакта шундый юллар китерелә:

Андыйн соң Чынгыз хан әйде: «Әй Кирәйет би, синең агачың юкә булсын, кошың каз булсын, ураның — бүре, тамгаң күз тамга булсын, сыйфаты ушбудыр (ассызык безнеке.— *М. Ә.*)[10].

Югарыда китерелгән фактлар XII гасырдан ук мәгълүм булган Кирәйет исемле татар кабиләсенең, Алтын Урда, Нугай Урдасы дәүләтләрендә катнашып, бүгенге татар, казакъ, каракалпак, үзбәк, нугай халыкларының этник тарихларына нисбәте барлыгын сөйлиләр.

Бу кабиләнең татар халкы этник тарихына да катнашы барлыгына безнең кулыбызда дәлил-чыганаклар бар. Алар, беренче чиратта,— татар шәҗәрәләре кульъязмалары. Кирәйетләр белән бәйле татар шәҗәрәләре Татарстанның Азнакай һәм Башкортстанның Бакалы төбәкләре белән бәйле. Ул язмаларның кайсылары — XIX гасырда, кайсылары XX гасырның урталарында кәгазьгә төшерелгән.

Кульъязма Кирәйет нәселе шәҗәрәләре беренче мәртәбә 1976—1981 елларда Азнакай төбәгендә уздырылган археографик экспедицияләр вакытында табылды[11].

Шәҗәрә текстларының Яңа Урсай авылында табылган версиясе матбугатта басылып чыкты[12]. Азнакай районы Урсай мәктәбе укытучысы Роберт Зариповның район газетасы битләрендә шәҗәрәгә бәйле мәкаләләр бастыруы хакында хәбәрләр бар.

Бүгенге көндә Кирәйет нәселе шәҗәрәсенең алты кульъязма версиясе саклангалыгы мәгълүм булды. Хәзер аларның һәркайсына аерым-аерым тукталып, тасвирлап узарбыз.

### I нче кульъязма версия*

Аның тексты 1983 елда Азнакай районы Чалпы авылында табылып, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульъязмалар Мирасханәсенә тапшырылды. Ул бер кульъязма китапның сәхифәләрендә теркәлгән. (Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсе: 99 кол., 1 тасвир, 5924 сак. бер.)

Кульъязманың сакланышы начар, гөмбәчекләр белән зарарланган, ул XVIII гасыр ахырларында

Русиядә эшләнгән сыек яшькелт төстәге кәгазьгә язылган, тышлыгы югалган, 17 ә 21,5 см зурлыктагы 138 кәгазьдән гыйбарәт. Текстлар имән каерысыннан эшләнгән яхшы гына кара белән язылган.

Китап — җыентык, анда кулъязма мөселман календаре, төрле догалар, дини мөнәҗәтләр, ислам тәгълиматы, елъязмалар һ. б. бар. Әсәрләр гарәп һәм татар телләрендә язылган.

Аның 92а битендә Кирәйет би шәҗәрәсе тексты бирелә:

1818 нче йылда ийүннең 11 нче көнендә яздым.

Мулла Әбелфәттах мулла Хәлилулла углы. Хәлилулла мулла Шәмсетдин ахун углы. Шәмсетдин Нугайбәк углы. Нугайбәк Хәсән углы. Хәсән Урсай углы. Урсай Җийаш углы. Җийаш Исәнгол углы. Исәнгол Сарубай углы. Сарубай Бүләк углы. Бүләк Аккүз углы. Аккүз Арслан углы. Арслан Алгунчы углы. Алгунчы Кугынчы углы. Кугынчы Кирәйет би углы. Кирәйет би Нугайдан килгән.

1498 сәнә Имән каласы Өфе аталды.

1319 йылда грамоталар күчерелгән.

806 йылында...

1817 сәнә.

1874 йыл үктәбердә башкортдан солдат алынды 21 йәшендәгене.

Борынгы татар кабиләсе Кирәйетнең Идел-Урал буйларында оешкан Нугай Урдасы составында булуы турында шәҗәрә кыйммәтле документ булып тора. Шәҗәрәдә китерелгән исемнәр гарәп һәм татар теле лексик байлыгы нигезендә ясалганнар. Тел материалы Кирәйет шәҗәрәсенең башкорт белән этник бәйләнеше булуын кире кага. Бу нәселнең, һичшиксез, башкорт сословиесендә булуы мөмкин.

Шәҗәрәдә китерелгән хронологик даталар да тарихи яктан кызыклы.

Мәсәлән, Уфа шәһәре урынында Имән каласы булу хакындагы хәбәр башка чыганакларда да күренгәли.

Кайбер хронологик даталар текст язылып бетмәү сәбәпле томанлы калалар, бары башкорт сословиесеннән солдат ала башлау гына ачык аңлашыла.

### 2 нче кулъязма версия

Аның кулъязмасы күренекле татар галиме Ризаэддин бине Фәхретдин кулы белән күчерелгән, эчтәлеге белән беренче версиягә бер яңалык та өстәми, бәлки, аның кимрәк дәрәҗәдәге күчермәсен генә тәшкил итә. Аның тексты галимнең Петербургтагы Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Петербург бүлегендәге архивында саклана (131 фонд.— 1 тасвир.— 50 эш бер.— 34а, 34б битләр).

### 3 нче кулъязма версия

Кулъязма текст гарәп графикасында 10 ә 16,5 см зурлыктагы элекке дәфтәр бите фрагментына карандаш белән язылган. Язылу датасы 1950 еллар булса кирәк.

Шәҗәрә тексты Башкортстан Республикасы Бакалы районы Яңа Урсай авылында 1976 елның августында Гарифьянова Мәрзиядән алынды:

Әүвәл бабабыз Нугайдан килгән. 1 нче — Кирәйәт би. 2 нче — Куганчы. 3 нче — Алганчы. 4 нче — Арслан. 5 нче — Аккүз. 6 нчы — Бүләк. 7 нче — Сарбай. 8 нче — Исәнгол. 9 нчы — Җийаш. 10 нчы — Урсай. 11нче — Хәсән. 12 нче — Нугайбик. Нугайбик угланлары: Җәркәй, Җармөхәммәд, Шәмсетдин, Хөрмәкәй, Сәлтәш, Шаммаз, Морадым, Габделваһаб, Котлызаман.

Нугайбик бабабызның угланлары тугыз булган.

Текстның кулъязмасы Казанда Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты кулъязмалар Мирасханәсендә 99 коллекция, I тасвирда, 93 эш берәмлеге булып саклана.

### 4 нче кулъязма версия

Текст гарәп графикасында 1950 елларда Марзия Гарифьянова тарафыннан күчерелгән ике бит мәктәп дәфтәренә теркәлгән:

**Урсай бабайларның тарих башы**

1817 нче йылда ийүннең 11 нче көнендә йаздым, мелла Әбелфәттах мелла Хәлилулла углы. Хәлилулла мелла Шәмсетдин ахун углы. Шәмсетдин Нугайбик углы. Нугайбик Хәсән углы. Хәсән Урсай углы. Урсай Җийаш

углы. Җийаш Исәнгол углы. Исәнгол Сарбай углы. Сарбай Бүләк углы. Бүләк Аккүз углы. Аккүз Арслан углы. Арслан Алгунчы углы. Алгунчы Куганчы углы. Куганчы Гирәйет би углы. Гирәйет би Нугайдан килгән.

1491 сәнә Имән каласы Өфе аталды.

1369 йылда грамоталар күчерә.

6008* йылда1 була бу Күнгүр...

1871 йылда үктәбердә башкортдан солдат алынды. 21 йәшендәгеләр.

1867 йылында йаздым мелла Мөхәммәдхафиз мелла Әбелфәттах Әлмәрхүм (углы) Нугайбәков. Тәмам.

Нугайбик бабамызның угланлары: Җәркәй, Җармөхәммәд, Шәмсетдин, Хөрмәкәй, Сәлтәш, Шаммаз, Морадым, Габделваһаб, Котлызаман.

Нугайбик бабабызның угланлары тугыз булган. Тәмам.

Карап укыгыз, танырсыз, сәлам белән Мәрзийә (Гарифьянова).

### 5 нче кулъязма версия

Азнакай районы Карамалы авылыннан булган Бүләк картның нәсел шәҗәрәсе авылның «Шәҗәрәләр китабы»на кертелгән. Аны безгә 1976 елның 19 августында Азнакай шәһәрендә яшәүче Бүләкова Мәймүнә һәм аның улы Сирин тапшырдылар. Әлеге ядкарь 22ә35,2 см зурлыктагы саргылт төстәге начар гына 7 бит кәгазьгә 1922 елның 4 декабрендә Шаһсолтан Әхмәтҗанов тарафыннан шәмәхә кара белән язылып төгәлләнгән.

Шәҗәрә китабында Карамалы авылына 1800—1805 еллар арасында Әсәй авылыннан күчеп килгән Солтанбәк, Зөбәйер, Кадрәч, Госман, Качкын, Габдерәфикъ, Байазит, Хәбибулла, Кинҗәгол, Мохсин, Бүләк, Мөэмин бабаларның нәсел шәҗәрәләре таблицалары бирелгән. Авыл халкы башкорт сословиесенә караган, ләкин ыру-кабилә бүленеше булмаган.

Шәҗәрәгә керештәге язмаларга караганда, килүчеләрнең кайберләре, ата-бабаларыннан ишетелгән хәбәрләр буенча, Нугай хан нәселеннән булган: Нугай хан, Киртә бай, Каракүз, Аккүз, Кугучы, Алгучы, Арслан, Бүләк, Сарыбай, Исәнгол, Дәүләтгилде, Таһир.

Җыентыкта китерелгән бабаларның берсенең генә исемен (Бүләк) әлеге Нугай хан шәҗәрәсе белән турыдан-туры бәйләп карарга мөмкинлек бар. Шунлыктан, урын да чикләнгәнлектән, бу хезмәттә фәкать Бүләк карт нәселен күрсәтергә булдык. Ихтимал, Карамалыга күчеп килүчеләрнең барысы да Нугай ханга ялганадыр. Ләкин моны архив чыганаклары белән расларга кирәк.

Шәҗәрә китабының кулъязмасы Казанда Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршындагы кулъязмалар Мирасханәсендә 99 коллекция, 1 тасвир, 111 эш берәмлеге булып саклана.

### Бүләк карт нәселе

*I буын*

1. Бүләк карт

*II буын*

| | |
|---|---|
| 2. Ихсан | 1 |
| 3. Исхак | 1 |
| 4. Мөхәммәдвәли мулла | 1 |
| 5. Мөхәммәдхөсәйен | 1 |
| 6. Мөэмин | 1 |

*III буын*

| | |
|---|---|
| 7. Камалетдин | 2 |
| 8. Сәлмән | 2 |
| 9. Шәмсетдин | 2 |
| 10. Җиһангир | 2 |
| 11. Бадахшан | 3 |
| 12. Габделгани | 3 |
| 13. Игътисан | 3 |
| 14. Әхмәтҗан | 3 |
| 15. Мөхәммәдхәсән | 4 |
| 16. Мөхәммәдвәли | 4 |

17. Моганниша 5
18. Әхмәдиша 5
19. Нәдерша 6
20. Шәрәфетдин 6
21. Җәлалетдин 6

*IV буын*

22. Сәгыйт 7
23. Таҗетдин 7
24. Гыйльман 8
25. Гыйльфан 8
26. Солтангәрәй 9
27. Дәүләтгәрәй 9
28. Солтангир 10
29. Габделвәли 10
30. Мөхәммәдгали 11
31. Мөхәммәдгариф 11
32. Мөхәммәдҗан 11
33. Мөхәммәдсабир 12
34. Шакир 12
35. Габделгали 12
36. Вәлиәхмәт 13
37. Бәдретдин 14
38. Мөхәммәдзакир 14
39. Мөхәммәдсадыйк 15
40. Мөхәммәдгариф 15
41. Мөхәммәдәмин 15
42. Әхмәт хаҗи 17
43. Мөхәммәт хаҗи 17
44. Мөхәммәт 18
45. Вәлиәхмәт 18
46. Әхмәт 18
47. Габдулла 18
48. Гәрәйша 18
49. Габделкаһир 18
50. Мөхәммәдҗан 19
51. Мөхәммәдша 19
52. Миңлевәли 20
53. Баһаветдин 21

*V буын*

54. Шәрәфетдин 23
55. Шәйхетдин 23
56. Габделихсан 25
57. Миңлебай 26
58. Гомәр 26
59. Ибраһим 27
60. Йагкуб 27
61.Минһаҗетдин 27
62. Миңлегали 28
63. Шакир 28
64. Әхмәтзакир 28
65. Габделгани 30
66. Әхмәтгали 30
67. Мөхәммәдвәли 30
68. Габделвәли 31
69. Миңлехәниф 31
70. Миңлегали 31
71. Миңле...*(танылмый)* 31

72. Мөхәммәдәмин 32
73. Зәки 34
74. Шәриф 34
75. Миңлегалим 35
76. Әхмәтхәбиб 35
77. Нуриәхмәт 36
78. Фазлыйәхмәт 36
79. Шаһиәхмәт 36
80. Шәрәфетдин 37
81. Сәлахетдин 37
82. Гаясетдин 37
83.Шаһсолтан 38
84.Шаһмөхәммәт 38
85. Суфийан 39
86. Сафуан 39
87. Мирсәйед 40
88. Мөхәммәдшәриф 40
89. Мөхәммәдхәниф 40
90. Шакир 42
91. Шәфигулла 43
92. Хөснулла 43
93. Мозаффар 43
94. Мөхәммәдшәриф 43
95. Мәхмүд 44
96. Нуриәхмәт 45
97. Әхмәтсәгыйт 45
98. Хәбибулла 46
99. Мөхлис 46
100. Габделһади 47
101. Габделхаликъ 47
102. Габделҗәмил 47
103. Хәбиб 47
104. Шәриф 47
105. Һәким 49
106. Мөхәммәдхафиз 50
107. Мөхәммәдшафикъ 50
108. Дәүләтша 51
109. Әхмәтша 51
110. Әхмәди 51
111. Мәрдәнша 51
112. Хәсәнша 51
113. Мөхәммәдхәбиб 52
114. Мөхәммәдзариф 52
115. Фатих 52
116. Мөхәммәдситдыйк 52

*VI буын*

117. Хәйретдин 54
118. (*танылмый*) 55
119. Кәшшафетдин 55
120. (*танылмый*) 55
121. Шәйхелислам 56
122. Кәлимулла 59
123. (*танылмый*) 59
124. Исхак 60
125. Исмәгыйль 60
126. Йосыф 60
127. Имаметдин 61

128. Габделҗәмил 65
129. Габделбәдыйк 66
130. (*танылмый*) 67
131. Миңлесәгыйт 70
132. Миңлезаһит 70
133. Миңлегалим 71
134. Мөхәммәдшакир 72
135. Әхмәтхан 72
136. Мөхәмматзәки 72
137. Хаҗимөхәммәт 78
138. Әнвәр 80
139. Рәйан 81
140. Рәис 81
141. Сирин (1941) 83
142. Сәйлун (1930) 83
143. Атлас (1944) 83
144. Рәйан 83
145. Сәйлун 83
146. Сирин (1948) 83
147. Мансур 84
148. Таҗимөхәммәт 84
149. Мисбах 84
150. Мөҗәһит 90
151. Хәниф 98
152. Хәмидулла 106
153. Габдулла 106
154. Хәбибулла 106
155. Габделгазиз дивана 106
156. Габделбәдыйк 107
157. Габделнәфыйк 107
158. Габделхаликъ 107
159. Газизулла 108
160. Әмирша 108
161. Шәһидулла 108
162. Фәтхулла 108
163. Сәйфулла 108
164. Фирүшаһ 109
165. ...нша (*танылмый*) 109
166. Фәрехша 111
167. Әхмәтвәли 112
168. Әхмәдиша 112

VII буын

169. Габделвәгыйз 158
170. Гәрәйша 160
171. Мөбарәкша 160
172. Хәбибулла 162
173. Кәлимулла 162
174. Галиулла 162
175. Хәмидулла 163
176. Сәмигулла 163
177. Сафиулла 163
178. Гәрәйша 164
179. Могыйн 164
180. (*танылмый*) 164
181. Габделвәли 165
182. Равил 165
183. Миңлегол 166

184. Габдулла 168

*VIII буын*

185. Гыймад 183

Карамалы карийәсенең булуында 1918 нче (йыл) 4 нче майга кадәр килеп китмеш кешеләр һәм хәзерге көндә исәнләре барчасы шунда җәдвәлләр эчендә тәмам язылды. Карамалы аулының йазучысы Шаһсолтан Мөхәммәдзакир углы Әхмәтҗанов 1922 нче йылда дикәбернең 4 сендә.

## 6 нчы кулъязма версия

Шәҗәрәнең бу зур гына версиясе Азнакай районы Урсай авылында яшәүче Мириханов Миргарифан (1903—1977) бабай төзегән дәфтәрдән археографик экспедиция вакытында — 1976 елның 12 августында — автографта язылган графикада күчереп алынды.

Миргарифан Мириханов язмасы нигезендә, аның оныгы Мириханов Назиф Мөҗәһид улы нәселнең киңәйтелгән зур тарихын 1999 елда урыс телендә язып төгәлли. Аның компьютерда басылган 69 битлек китабында төрле характердагы информацияләр бирелә. Әлбәттә, алар, бер яктан,— бик кызыклы, икенче яктан — кайберләрен тасвирлау өчен өстәмә чыганаклар табу таләп ителә. Назиф Мириханов, үзенең туганнары турында, бабасыннан соң да күп мәгълүматлар туплап, Кирәйет би шәҗәрәсен XX гасыр ахырына кадәр тулыландырып, бик мөһим эш эшләгән. Аның хезмәтен XXI гасырда да дәвам итүчеләр табылыр дип өметләнергә генә кала.

Миргарифан бабай төзегән шәҗәрә тексты 12 битлек мәктәп дәфтәрендә гарәп хәрефләре белән язылган иде. Түбәндә шул текстны, хәзерге татар графикасына күчереп, тулаем рәвештә бирәбез:

Нәсел-нәсәб Нугайбек бабайдан йугары кем углы кемнең әткәсе җәдүәле. Буны йазгучы күчереп Мирихан углы Миргарифан.

1871 нче йылда 11 нче ийүн көнендә яздым. Мелла Әбелфәттах мелла Хәлилулла углы. Хәлилулла мелла Шәмсетдин ахун углы. Шәмсетдин Нугайбек углы. Нугайбек Хәсән углы. Хәсән Урсай углы. Урсай Җийаш углы. Җийаш Исәнгол углы. Исәнгол Сарыбай углы. Сарыбай Бүләк углы. Бүләк Аккүз углы. Аккүз Арслан углы. Арслан Алгунчы углы. Алгунчы Куганчы углы. Куганчы Кирәйет би углы. Кирәйет би Нугайдан килгән кеше.

1491 нче йылда Имән каласы Уфа дип аталган.

1319 нчы йылда грамоталар күчерә.

6008 нче йылда була бу Кунгур.

1871 нче йылда үктәбер айында башкортдан салдат алынды, 21 йәшендәгеләр.

Беренче прием Хисамиев Камалетдин.

2 нче — Монасыйб Мәрдәнша углы.

1871 нче йылда йаздым мөәзин Мөхәммәдхафиз мелла Әбелфәттах әл-мәрхүм (углы) Нугайбеков. Тәмам.

Нугайбек бабамызның угланлары тугыз булган. Кыз балалары билгесез.

1 нчесе — Җәркәй Нугайбек углы.
2 нчесе — Җармөхәммәд Нугайбек углы.
3 нчесе — Шәмсетдин Нугайбек углы.
4 нчесе — Хөрмәкәй Нугайбек углы.
5 нчесе — Сәлтәш Нугайбек углы.
6 нчысы — Шаммаз Нугайбек углы.
7 нчесе — Морадым Нугайбек углы.
8 нчесе — Габделваһаб Нугайбек углы.
9 нчысы — Котлызаман Нугайбек углы.

### I

### Җәркәй Нугайбековтан таралган балалар

Җәркәй бабайның 1 нче углы — Бәләкәй Гәрәй, 2 нче углы — Хәлилулла, 3 нче углы — Галиәкбәр, 4 нче углы — Миһран, аның углы жук.

Бәләкәй Гәрәйнең угыллары: 1нчесе — Фәхретдин, 2 нчесе — Насретдин.

Фәхретдин углы Шәйхетдин, Шәйхетдин углы Габдулла.

Насретдин углы Шәйехгариф.

Галиәкбәрнең угыллары: 1 нчесе — Галиәхмәт, 2 нчесе — Морзахан, 3 нчесе — Галиәскәр, 4 нчесе — Галиәхмәт, аның углы Казыйхан. Морзаханның угыллары Мөхәммәддин, Галиулла, Галиәскәр углы Зөлкарнай сугышта үлгәннәр.

Җәркәй бабайдан Әхмәтсәгыйт булган. Әхмәтсәгыйтнең 1 нче углы — Сибгатулла, 2 нче углы — Сабирҗан, 3 нчесе — Мөхәммәдшәриф, 4 нчесе — Закирҗан.

Сибгатулланың угыллары: 1 нчесе—Миңлеәхмәт, 2 нчесе — Камил.

Сабирҗан углы Аксак Галимҗан.

Яңа Урсай Шәриф углы Әхмәтлатиф, Мөхәммәтлатиф, Закирҗан сугышта үлгән.

## II

## Җәрмөхәммәт Нугайбековтан таралган балалар

Җәрмөхәммәт бабайдан таралганнар: 1 нчесе — Гали хәзрәт (чын исеме Галибай, 1848 нче елда 48 яшьтә вафат), 2 нчесе — Кыргыз Гәрәй. Гали мелла угыллары: 1 нчесе — Габделлатиф, 2 нчесе — Габделфәттах, 3 нчесе — Әбелмөннийә, 4 нчесе — Әбелхарис; 5 нчесе кыз бала — Биби (Кичүчат авылында Нәҗметдин бине Фәсихетдин бине Собханколда кияүдә була)[13].

Кыргыз Гәрәй углы Мөхәммәдкасыйм, Касыйм углы Хафиз, Хафиз углы Мөхәммәдзакир.

Гали мелла углы Габделфәттах — Аксак мелла — укытучы булган. Фәттах улы Асафетдин. Асафетдин углы Гавариф (Мөхәммәдгариф) сугышта үлгән.

Мөэнних (Әбелмөннийә) углы — Вагыйз.

Харисның (Әбелхарис) углы юк.

Габделлатиф угыллары: 1 нчесе — Галәэтдин, 2 нче углы — Мислахетдин, 3 нчесе — Кәшшафетдин. Галәэтдин углы Габдрахман сугышта үлгән.

Мислахетдиннең бер углы бар—Миргалим.

Кәшшафетдиннең бер углы булган — Габдулла.

Җармөхәммәт бабай углы Хәбибрахман. Хәбибрахман угыллары: 1 нчесе — Төхфәтулла, 2 нче углы — Мөхәммәдшәриф; Мөхәммәдшәриф угыллары: 1 нчесе — Мөхәммәдгариф, 2 нче углы — Мөхәммәдшакир; Мөхәммәдгариф угыллары: 1 нчесе — Мөхәммәдсалих, 2 нче углы — Миргасыйм.

Мөхәммәдсалихның угыллары: 1 нчесе — Миргазийан, 2нчесе — Мөҗәйдан, 3 нчесе — Гариф. Гариф углы Миргасыймның 2 углы бар: 1 нчесе — Наил, 2 нчесе — Нияз.

Хәбибрахман углы Дәүләтшаның 1 нче углы —Җиһанша, 2 нчесе — Әхмәдиша. Җиһанша углы Сәйетша. Сәйетша углы Вәлиша.

Җармөхәммәд бабай углы Төхфәтулланың угыллары: Рәхмәтулла, Зиннәтулла.

Хәбибрахманның угыллары: Дәүләтгәрәй, Мөхәммәдгәрәй. Мөхәммәдгәрәйнең угыллары: 1 нчесе — Шәңгәрәй, 2 нчесе — Әхмәтҗан, 3 нчесе — Әхмәтхан. Әхмәтханда ике ир бала бар.

Әхмәтҗан углы Мөхәммәдҗан.

Дәүләтгәрәй углы Мөхәммәдгарифтан Мирзасалих, Мөсәгыйт, Латиф исемле ир балалар туган. Мирзасалих углы Фәргат.

## III

## Шәмсетдин ахун Нугайбековтан таралган балалар

Шәмсетдин ахун углы Хәлил мелла. Хәлил угыллары: 1 нчесе — Фәттах, 2 нчесе — Әбелфатих, 3 нчесе — Сабур мелла, 4 нчесе — Шәкүр мелла, аның угыллары Мөхәммәдшакир, Хәбибулла. Мөхәммәдшакир углы Фатих сугышта үлгән.

Әбелфатих мелла угыллары: Мөхәммәдхафиз мөәзин, Закир мулла, Хафиз мөәзин, аның 1 нче углы — Мөхәммәдгариф,
2 нчесе — Мөхәммәдфазыл, 3 нчесе — Сөләйман.

Сабур мелланың углы Мөхәммәдсабир.

Хәлил мелла углы чулак Фәттах, аның 1 нче углы — Мирхәйдәр, 2 нчесе — Мөхәммәдшәриф, 3 нчесе — Мөхәммәдзәки — сугышта үлгән. Чулак Фәттах беренче булып, Ык йылгасын буып, тегермән корган.

Шәмсетдин ахун угыллары: Сәйет баба, Дәүләтша, Әфләтун.

Сәйет баба углы Сәхибгәрәй. Сәхибгәрәй угыллары: 1 нчесе — Әхмәтгәрәй, 2 нчесе — Арслангәрәй. Әхмәтгәрәй углы Мөхәммәдфазыл. Арслангәрәй углы Мөхәммәдсалих.

Дәүләтша углы Сәгъди мелла. Аның 1 нче углы — Мөхәммәдшәриф мелла, 2 нчесе — Габдрахман, 3 нчесе — Мөхәммәдгариф. Мөхәммәдшәриф мелла угыллары: 1 нчесе — Фәтхелбаян, 2 нчесе — Багис, 3 нчесе — Нурлыгаян, 4 нчесе — Мөхәммәдфатих, аның углы Фәтхелбаян.

Әфләтун угыллары: 1 нчесе — Шаһимәрдән, 2 нчесе — Арслан, 3 нчесе — Әмирҗан, 4 нчесе — Зиннур. Арслан углы Гәрдан.

Әмирҗан угыллары Илдархан һәм Миргазийан. Илдархан угыллары Мирзахан, ... (*таныймый*), Фәтхелбаян.

Шаһимәрдән һәм Зиннурның балалары юк.

## IV

## Хөрмәкәй Нугайбековтан таралган балалар

Хөрмәкәй Нугайбек углы кантун булып йәшәгән. Хөрмәкәй угыллары: 1 нчесе — Шәңгәрәй кантун, 2 нчесе — Равил.

Шәңгәрәй кантун угыллары: 1 нчесе — Әхмәтгәрәй, 2 нчесе — Солтангәрәй, 3 нчесе — Әсмандийар, 4 нчесе — Мохтар.

Әхмәтгәрәй угыллары: Сарыйг, Гаскәр һәм Бәхтигәрәй. Гаскәр углы Искәндәр. Искәндәр углы Мөхәммәдтакый. Бәхтигәрәй угыллары: 1 нчесе — Батыргәрәй, 2 нчесе — Солтангәрәй мелла Нурмөхәммәт, 3 нчесе — Галимәрдән.

Равил углы Мирихгәрәй. Мирих угыллары: 1 нчесе — Салихҗан, аның углы Әмирҗан, аның углы Габбасҗан сугышта үлде.

Мирих угыллары: 1 нчесе — Насыйрҗан, 2 нчесе — Мөхәммәдгариф — дворән булган.

Уфа, Ак Идел, Кама буйлап, Сембер, Казан, Саратау, Самар, Оренбург, Троицки да Хөрмәкәй кантун кул астында булган, һәм алар күп кенә армия тотканлар. Хөрмәкәй кантун углы Шәңгәрәй кантун булып шулай ук йәшәгән.

Шәңгәрәй кантун 1878 нче йылда үлгән. Бик күп болын, әрәмәлек һәм урманны үз милке итеп биләгән. Йорт әйләнәсе бик калын урман булган: өйәнке, карама, кайын, нарат, шомырт, балан, карлыганнар үскән. Анда качкынлар йаткан.

## V

## Сәлтәш Нугайбеков углы, шундан таралган балалар

Сәлтәш углы Шаһиморат. Аның угыллары: Әбүбәкер, Шәйхелислам. Әбүбәкер угыллары: Мөхәммәдгата, Сафа, Вәли. Шәйхелислам угыллары: Әхмәтлатиф, Әхмәтсалих. Әхмәтсалих углы Мөхәммәдзакир.

Мелла Сәлтәш углы Мөслахулла. Мөслахулла угыллары: Габделхәй, Әхмәтхан. Әхмәтхан мелла угыллары: Габделбәр, Габделразак, Миһрихан. Әхмәтхан мелла угыллары: Сәлахетдин, Габдулла, Миргарифан. Миргарифан угыллары: Мөҗәһидан, Мирхафизан. Мөҗәһидан угыллары: Надиф, Надил, Наил. Мирхафизан угыллары: Багис, Легендар, Фәнис (углы Рәйан), Мийәссәр. Әхмәтхан мелла угыллары: Мирмәгъсүм, Касыймхан. Касыймхан угыллары: Шакирҗан, Салихҗан, Мөхәммәдхан. Әхмәтхан мелла угыллары: Мөхәммәдпарса, Фәиз, Рәшит.

Шаһимөхәммәт Сәлтәш углы. Шаһимөхәммәт угыллары: Мирхәйдәр (угыллары — Нурмөхәммәт, Нургали), Җиһангир, Мөхәммәдҗан, Миргали (угыллары — Шәвәли, Габдрахман, Мөхәммәдҗан, Мөхәммәдсафа).

Ачуак Сәлтәш углы. Аның угыллары: Нурмөхәммәт, Габдулла, Хаҗимөхәммәт, Габделгани (углы Сәгыйр). Шаһимәрдән Нурмөхәммәт углы.

Җиһангир Сәлтәш углы. Җиһангирның 1 нче углы — Мөхәммәдҗан, 2 нчесе — Мөхәммәдшәфыйк, 3 нчесе — Мөхәммәдвәли.

Мөхәммәдҗанның 1 нче углы Гыймадетдин элекке сугышта үлгән, 2 нче углы — Мөхәммәдхан, 3 нчесе — Борһан, 4 нчесе — Әхмәтхан аксак, 5 нчесе — Салихҗан. Мөхәммәдхан угыллары: Галимҗан, Шәрифҗан. Борһан углы Мифтахетдин, аның угыллары — Фәнис, Айрат.

Шәфыйк угыллары: Мөхәммәдсабир, Салих аксак, Фатих.

Мөхәммәдвәли угыллары: Садыйк, Мөхәммәдгата, Мөхәммәт.

Сәлтәш баба углы Гәрәйша. Гәрәйша углы Хөрмәкәй, Хөрмәкәй углы Шаһгасыйм. Шаһгасыйм угыллары: 1 нчесе — Габдрахман — Ватан сугышында үлде, 2 нче углы — Мәрданша, 3 нче углы — Йәһүдә. Мәрданшаның 1 нче углы Илкәм.

Хөрмәкәй углы Гыймаделислам. Гыймаделисламның 1 нче углы — Фоат, 2 нчесе — Баис. Гыймаделислам үзе Ватан сугышында үлде. Баисның углы Марат.

## VI

## Шаммаз Нугайбековтан таралган балалар

Мәрданша Шаммаз углы, Шаһиморат Шаммаз углы. Мәрданша угыллары: 1 нчесе — Монасиб, 2 нчесе — Гыйрфан, 3 нчесе — Мөхәммәдзариф, 4 нчесе — Госман.

Монасиб угыллары: 1 нчесе — Миргасим, 2 нчесе — Габдрахман.

Мөхәммәдзариф углы Мөхәммәдгариф.

Госман угыллары: Мөхәммәдхан, Миңнехан, ...*(танылмый).*

Шаһиморат угыллары: Фәхретдин, Шәрәфетдин, Кәшшафетдин. Фәхретдин угыллары: Шаһимәрдән, Мирзасалих.

Шәрәфетдин углы Сәләхетдин. Сәләхетдин углы Хәләфетдин. Хәләфетдин углы Ләис.

Кәшшафетдин угыллары: 1 нчесе — Сәгыйрь, 2 нчесе — Камалетдин, 3 нчесе — Шәмсетдин. Шәмсетдин углы Сәләхетдин. Сәләхетдин углы Мирфайаз.

Кәшшаф углы сукыр Баһау.

Мәрдәнша углы Гыйрфан. Гыйрфан углы Солтангәрәй. Солтангәрәй патша хезмәтендә үлгән.

## VII

## Морадым Нугайбековтан таралган балалар

Морадым углы Могътәсим. Могътәсим угыллары: 1 нчесе — Мөхәммәдша, 2 нчесе — Габдулла, 3 нчесе — Игътисам, 4 нчесе — Әхмәтҗан, 5 нчесе — Мөхәммәдҗан. Мөхәммәдша угыллары: Сәйетша, Хәйрелгабидин.

Габдулла угыллары: Хәбибулла, Хәмидулла.

Игътисам углы Газизхан.

Әхмәтҗан углы Мөбарәкҗан.

Морадым угыллары: Мозаффар, Мөхәммәдкәрим. Мозаффар угыллары: ...*(танылмый)*, 2 нче углы — Мөхәммәдгәрәй. Мөхәммәдгәрәй углы Әхмәтлатыйп. Әхмәтлатыйпның 2 углы бар: 1 нчесе — Мәүлүтдин, 2 нчесенең исеме билгесез.

Мөхәммәдкәримнең ир баласы юк.

Мөхәммәдгәрәй углы Асылгәрәй. Асылгәрәй углы Миргазийан.

Мөхәммәдгәрәй углы Миргасыйм. Миргасыйм угыллары: 1 нчесе — Миргайаз, 2 нчесе — Мирзасалих — сугышта үлгән.

Мөхәммәдгәрәй углы Мирзаһит та сугышта үлгән.

### Ваһаб байныкылар

Галиулла углы Кәшшафетдин. Кәшшафетдин угыллары: Мирзаһит, Әкмалетдин. Әкмалетдин углы Шәрифулла.

Галиулла углы Хәбибулла. Аның 1 нче углы Хәмидулла мелла. Аның ике углы бар: Гарби, Хәнәфи.

Хәбибулла углы Зариф. Аның углы юк.

Шәрифулла углы Мөхәммәдшакир армиядә үлде. Галиулла углы Мәслахетдиннең 1 нче углы Хәйретдин, 2 нчесе — Афзалетдин, 3 нчесе — Гыймазетдин, 4 нчесе — Мөхәммәдсабир сугышта үлделәр.

Галиулла углы Шәрифулланың 1 нче углы Габделгаффар. Габделгаффарның 2 углы бар. 1 нче углы Габделбасыйр, аның 2 углы бар. Габделгаффарның 2 нче углы Габделгани. Аның 2 углы бар.

Шәрифулла улы Габделмөссәвир, аның ир баласы юк.

Афзалетдин углы Гыймадетдин. Гыймадетдин углы Илшат.

Галиулла углы Хәлилулла, аның углы Талибулланың 1 нче углы Гарифулла сугышта вафат, 2 нче углы — Такыйулла (аның 2 углы бар), 3 нче углы — Рафаэль, аның бер углы бар.

Галиулла углы Шәфыйгулланың углы Сәгадәт. Аның өч углы бар. Сәгадәт улы Фәрагат армийәдә үлде. ...(*танылмый*), 2 нче углы Ваһаб, аның углы Әхмәтбай. Әхмәтбай углы Мирсәйет 1916 йылда Чалпы йулында буранда үлде. Мирсәйет углы Габдрахман Кәрпи белән Урсай арасында буранда үлде 1911 йылда.

Галиулла углы Хәлилулланың углы Заһидулла. Заһидулланың углы Хәмидулла, аның углы Әсгать. Әсгать углы Айрат.

Хәмидулланың углы Рәис. Рәис углы Рәфис.

Заһидулла углы Газизулла, аның 2 углы бар.

## VIII

## Габделваһаб Нугайбековтан таралган балалар

Ваһаб бабай угыллары: Мөхәммәдвәли, Әхмәтҗан, Әхмәтбай, ...(*танылмый*).

Мөхәммәдвәли бабайның 1 нче углы Габделхәким, 2 нчесе — Мөхәммәдзагир, 3 нчесе — Габделгани, 4 нчесе — Җиһансивар.

Габделхәким бабайның угыллары: Габдерәүф, Габделһади.

Загир бабай угыллары: 1 нче углы — Гарифҗан, 2 нчесе — Мөхәммәдхафиз, 3 нчесе — Хөсәйен.
Габделгани бабай угыллары: Әшрәфҗан, Салихҗан.
Гарифҗан, Хөсәйен — телсез.
Хафиз агай угыллары: 1 нчесе — Салих, 2 нчесе — Фатих.
Габдессаттар Ваһаб углы. Габдессаттар бабай угыллары: 1 нчесе — Габделгали, 2 нчесе — Габделвафа, 3 нчесе — Габделҗаппар, 4 нчесе — Галиулла, 5 нчесе — Хөснулла.
Габделгали угыллары: Мөхәммәдзакир, Габделгани. Мөхәммәдзакир углы Мөхәммәдгариф. Габделгани угыллары: Габдулла, Габделхан, Габдрахман, Миңлегалим.
Габделҗаппар углы Мөхәммәдшакир. Мөхәммәдшакир угыллары: Миргасыйм, Миргали, Мөхәммәдшәйех, Мөхәммәдтаиб (аның баласы юк), Мөхәммәдгариф.
Габделҗаппарның углы Хөснулла. Хөснулла углы Хәмидулла.
Галиулла угыллары: 1 нчесе — Хәлилулла, 2 нчесе — Кәшшафетдин, 3 нчесе — Хәбибулла, 4 нчесе — Шәрәфетдин, 5 нчесе — Мәслахетдин.
Хәлилулла угыллары: Заһидулла, Талибулла, Шәфигулла, Сәмигулла.
Ваһаб бабай угыллары: Әхмәтҗан, Миңлехан, 3 нчесе — Какай Гәрәй.
Әхмәтҗан углы Әхмәтсәгыйт. Әхмәтсәгыйт углы Гарифҗан. Гарифҗан углы Салихҗан.
Миңлехан угыллары: 1 нчесе — Габдеррәкыйб, 2 нчесе — Мөхәммәдҗан, 3 нчесе — Әхмәтҗан.
Какай Гәрәй углы Гыйлаҗетдин. Гыйлаҗетдин угыллары: Зыятдин, Миргаяз.
Ваһаб бабай углы Әхмәтвәли. Әхмәтвәли углы Әхмәтшәриф. Әхмәтшәриф углы Әхмәтзәки. Әхмәтзәки углы ...(*танылмый*).
Ваһаб углы Хәбибулла. Хәбибулланың углы Хөснулла. Хөснулланың угыллары: 1 нче углы —Габидулла, 2 нчесе — Шәйдулла, 3 нчесе — Лотфулла, 4 нчесе — Газизулла. Габидулла угыллары: Мәгъсүм, Мокътәсим.
Лотфулла, Шәйдулланың уллары күп.
Хәбибулла углы Вәлиулланың угыллары: Әбүнәис, Миңлехан.
Хәбибулла углы ...ланың (*танылмый*) углы Сәмигулла.

## IX

## Котлызаман Нугайбековтан таралган балалар

Котлызаман углы Сәйетпаттал. Аның угыллары: Габдессәлам, Габдессаттар, аларның ир балалары юк.
Котлызаман углы Хәсән. Хәсән углы Габдулла. Аның углы Мөхәммәдрәхим, аның углы Мөхәммәддин сугышта үлгән.
Габдулланың углы Хөсәйен. Хөсәйен угыллары: 1 нчесе — Сөләйман, 2 нчесе — Хәсәншәйех, 3 нчесе — Әбүталиб.
Габдулла углы Сафиулла, аның углы Сәгыйт.
Котлызаман углы Габделгазиз. Габделгазиз углы Карамулла. Карамулла угыллары: Миргазийан, Хәсән.
Габделгазиз углы Габделҗәлил. Габделҗәлил угыллары: Җәмил, Мәгъсум.
Котлызаман углы Солтангали. Солтангали углы Арслангали. Арслангали угыллары: 1 нчесе — Шаһгали, 2 нчесе — Сәйетгали, 3 нчесе — Миңлегали, 4 нчесе — Галирази.
Шаһгали балалары: кызы Ганҗә (1925 елда туган, Тымытык авылында яши), улы Рафаэль (Урсай авылында яши), кызы Вилена (Урсай авылында яши).
Ганҗә балалары: Сәлим (Мәскәүдә), Галим Убайдович Абдуллаев (1951—1997) — юстиция генералы, Татарстан Республикасы Югары Суды коллегиясе әгъзасы, Тымытык — Казан юлында автоһәлакәттә үлде. Шуннан бер ел узгач, Ганҗә улы Сәлим (1948—1998) Ык елгасында батып үлде.
Галирази уллары Ардинат һәм Айрат Әлмәт шәһәрендә яшиләр. Ардинат Галирази улы Нугайбеков — «Елховнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе җитәкчесе. Айрат Галирази улы Нугайбеков — «Татнефть» Акционерлык җәмгыятенең ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү бүлеге баш табибы.
Котлызаман углы Габдерәкыйб. Габдерәкыйб углы Габделмәҗит, Габделмәҗит углы Газиз.
Котлызаман углы Хәмидулла. Хәмидулла угыллары: Галиулла, Гарифулла, Зәйнулла, Нәбиулла, Хәлиулла, Гәрәйша.
Гарифулла углы Нигъмәтулла угыллары: Галимҗан, Мәгариф.
Гәрәйша угыллары: Мөзайан, Фәнис, Миршәрип.

Кирәйет би угыллары берлән Уфадан күчеп, Җийаш һәм Әҗми тирәсендә Наратлы Чокыр дигән җирләрдә тормыш иткәнләр.
1040 нчы йылларда кайсы бабай утырганы билгесез. Андан соң Карпи йылгасы буйына утырганлар. Шул

вакытларда Пасмараудан Карпийев дигән фамилийәдә бер байар килеп утырган. Урсай бабайлар, байардан куркып, Ык йылгасы буйында тау кырласына утырганлар. Карпийев байар үз кул астына күп кенә рус крәстийәнләрен туплап, Ык йылгасын буап, шул ук крәстийәнләрдән күлдән күлгә казытып, тегермән кордырган. Ул тегермән тартмаган. Ул күлләрне канау дип атаганлар. Шунлыкдан, байлар белән мәслихәтләре китеп, Ык йылгасының йугары йагына — Сукайыш суы буйына утырганлар. Бу урында, Чыршы күле буйында, Йүкәле Түбә дигән калын җүкә урманы булган. Өйләрне шул урмандан йасаганлар. Урсай бабайның угыллары бик укыган булганлар: кайсы — мулла, ахун, кайсы — кантун, кайсы — вайынный начальник.

1300 нче йылларда булырга кирәк, акрынлап, халыклар җыйылып утыра башлаганлар, күпме гомер кичергәнләре мәгълүм түгел. Каберлекләре Тымытык йулы буйында, Акчарлак күле буйында булган. Урсай бабай йанына Исхак бабай, Бикиев һәм Карачев бабай килеп, типтәрләр бергә гомер иткәнләр.

1830 нчы йылларда үзара тынгысызлык туып, башкортлар Коры елганың түбән йагына күчә башлаганлар. Нугайбек бабай (5) углын алып Чалпыга күчкән. Нугайбек бабайның кабере Чалпыда иске зиратта күмелгән, йазган ташы бар.

Беренче Урсайдагы зират — күпер башында йугары йакта, иске каберлек — Чалпы ауылында. Күптөрле халык ойышкан тигезсезлек туганлыктан, башкортлар 1872 нче йылда Урсайга күчкәнләр. Шундан соң 1918 нче йылга кадәр Урсайда йәшәгәнләр, тыныч йәшәгәнләр.

1877 нче йылда җир бүлү башланган. Халык арасында кычкырыш күп булганлыктан, Урсай авылын куркыту өчен, патша тарафындан убжурный каманда килгән: 250 салдат, мәгәр зыйан салмаганлар, 15 көн торып киткәнләр.

(1900) нче йыл белән (1905) нче йылда беренче рибалүтсийә кузгалган. Патша тарафыннан басканнар.

Миргарифан Мириханов төзегән әлеге «Кирәйет би шәҗәрәсе» тел тарихы һәм, гомумән, тарих өчен кызыклы язма истәлек булып калган. Анда бер нәселнең тарихы мисалында бөтен халыкның үткән юлы чагыла. Әлбәттә, автор үзенең хезмәтендә бөтен мөмкинлекләрен файдаланып бетерә алмаган, чөнки анда һәр шәхес буенча тасвирлап киткәндә генә дә күпме вакыйгалар чагылыр иде. Гади авыл кешесенең шул кадәрле зур нәсел тарихын язып калдырган дәфтәренә без хөрмәт белән карыйбыз.

Югарыдагы материалларга безнең тарафтан фәкать тасвирлау максаты гына күздә тотылып, Кирәйет би нәселе тарихына киң тарихи экскурслар ясалмады. Фәкать документаль булган эпиграфик мәгълүматларны, халык телендә йөргән риваятьләрне һәм язма документларда сакланган кайбер конкрет фактларны гына искә алып үтәргә булдык.

Нәселдә Кирәйет бидән соң иң мәгълүм тарихи шәхес булып Нугайбек Хәсән улы тора. Аның хакында безгә беренче мәртәбә 1976 елда Азнакай районы Чалпы авылындагы өлкән мәгариф ветераны Зөфәр ага Мортазин сүзләре һәм язмалары аша хәбәрдар булырга туры килде (ул 1895 елда туган). Зөфәр ага үзе ишеткән риваятьне зур күләмле «Чалпы авылы тарихы» исемле кулъязмасына да керткән иде. Аның эчтәлеге кыскача түбәндәгечә бәян ителә:

Ык буендагы татар авылларын 1740 нчы елларда көчләп башка урыннарга күчереп утырту бара. Бу эшне гаскәри көчләргә йөклиләр. Солдатлар, авылларга кереп, халыкка иң кирәк ашау әйберләрен дә алдырмыйча өйләреннән куып чыгаралар һәм, көтү шикелле куалап, каядыр алып китәләр. Шул вакытларда кайбер кешеләр яңа туган яшь балаларын урман араларына илтеп, агачка бишекләре белән асып китәләр. Урсай авылыннан Хәсән старшинаның да хатыны яңа гына ир бала тапкан була. Алар да балаларын, хәүфтән куркып, урманга илтеп яшергән булалар. Нугайбек крепосте тирәләрендә яшереп саклаганга, малайга исемне дә Нугайбек дип кушалар.

Нугайбекны хәрби эшкә укыталар. Ул укуын бетергән елларда Пугачев кузгалышы килеп чыга. Нугайбек патша армиясендә командир-старшина хезмәтендә йөри. Аның отрядын Пугачевка каршы сугышка җибәрсәләр дә, Нугайбек үзенең командасы белән пугачевчылар ягына чыгып сугыша.

Ләкин пугачевчылар җиңелә, Нугайбекны да патша гаскәрләре әсир итеп алалар, һәм ул суд аша асылып үтерүгә хөкем ителә.

Нугайбекның атасы Хәсәннең баласын югалтасы килми, төрмә, суд юлларында йөреп, улын җәзадан коткару чараларын эзли. Җәзалауны башкаручылар Хәсән белән килешеп, аңа ярдәм итәргә булалар. «Хәзер суд чыгарган карарны үзгәртеп булмый, без аны черек бауга асарбыз. Әгәр асылган кеше баудан өзелеп төшсә, димәк, аның гаебе юк, акланган булып санала»,— дигәннәр.

Шулай итеп, Нугайбек Хәсән улын черек бауга асалар, ул, өзелеп төшеп, исән кала. Шуннан соң 1775 елда Нугайбекның үз хуҗалык эшләрен алып баруы хакында документ билгеле.

Халык Нугайбекның үзе хакында шуннан артык хәбәрләр белми, аның тугыз улы үскәнлеге һәм

аларның холыклары турында гына кыска хәбәрләр бар.

Нугайбек Хәсән улының туган авылы Чалпы дип атала. Чалпы авылын 1704 елда Шикәрле Каен авылыннан татарлар (типтәр сословиесендәге) килеп корганнар. Чалпы авылында Шикәрле Каеннан килгән ике зур нәселнең шәҗәрәләре дә саклана. Нәселләрнең берсе — Җанморза, икенчесе Йөзкәй дип аталганнар[14]. Чалпы даими татар авылы булып кала биргән.

XVIII гасыр документларында Нугайбек Хәсән улын да Казан өязе татар старшинасы дип атыйлар[15].

Нугайбек Хәсән улы кул астындагы баш күтәрүчеләр отряды 1774 елның 14 январенда Зәй крепостен кан коймый гына ала, ләкин, патша гаскәрләре басымына чыдый алмыйча, шул ук елның 16 январенда, Зәй ныгытмасын ташлап, Кәшер авылына килеп туктыйлар[16].

Нугайбек Хәсән улы шәхесенә кагылышлы документ чыганаклар Азнакай төбәгендәге Чалпы һәм Урсай авылларының зиратларында ачыкланган кабер ташлары язмаларында да чагыла.

Азнакай төбәгенә 1976 елны фәнни археографик экспедиция белән килгәч, Чалпы авылында булган чакта, Зөфәр ага Мортазин, Нугайбек Хәсән улының кабере иске зиратта булырга тиеш, дигән иде, ләкин аның кабер ташы булу хакында бер сүз дә әйтә алмады.

Без исә Чалпы авылының иске, инде мәетләр күмелми торган зиратында Нугайбек Хәсән улы һәм аның балаларының кабер ташлары сакланганлыгын ачыкладык. Беренче таштагы язмага караганда, Нугайбек Хәсән улы 1216 һиҗри, 1802 милади елда үлгән була.

**Башка ташлардагы мәгълүматлар:***

**N№ 2**

1. Әл-мәрхүм Сәлтәш Нугайбек
2. углы, Аллаһу Тәгаләи рәхим кыйлгай иде. Тарих
3. ... 1831 йылда ...

**N№ 3**

1. Әл-мәрхүм Йармөхәммәд бине Нугайбек
2. дарел-фанадин дарел-бакайа
3. рихләт кыйлды. Аллаһу Тәгалә рәхим
4. кыйлгай иде. Рәхмәтә вә сәгатә
5. 1833 йылда, синтәбердә
6. Мөхәммәдгәрәй хәраҗәте ...
7. Сәнгате фәкыйрь Мөхәммәд ...

**N№ 4**

1. ...
2. мелла Йәркәй мәрхүм
3. бине Нугайбак углы тарих
4. вәләдә 64 сәнә фи мәсихия 1840 нчы сәнә ...

(64 яшьтә 1840 елда үлгән) һ. б.

**Урсай авылы зираты ташлары текстларыннан**

**N№ 1**

1. Тарих румийә илән
2. 1830 йылда Дәүләтша ...
3. Кормәкәй углы илле йәшендә
4. дарел-фанадин дарел-бакайа рихләт кыйлдый.
5. Аллаһу рәхмәт әйләсен.

**N№ 2**

...Шәмсетдин бине Нугайбек.

**N№ 3**

1. Бу кабердә Кормәкәй
2. Нугайбак углының
3. ...ның төрбәседер. 1820 сәнә
4. гыйнварның 1 көнендә.

Нугайбек Хәсән улы һәм аның балалары турында нәселләрендә кызыклы истәлекләр саклана. Шәҗәрәдә искә алынган Ардинат Галирази улы Нугайбеков үзенең бабаларыннан булган Хөрмәкәй Нугайбеков һәм аның улы Шәңгәрәйнең XIX йөз башында Ык буе зонасындагы 12 нче кантунның җитәкчеләре булуларын сөйләде. Алар 1812 елгы урыс-француз сугышында Наполеон гаскәрләрен тар-мар итүгә өлеш кертеп, Парижны штурмлауда катнашканнар. Хөрмәкәй белән Шәңгәрәй хөр фикерле кешеләр булып, властьларның халыкның хокукын кысуына каршы юнәлтелгән протест белдерергә дә җөрьәт иткәннәр. Шушы кыюлыгы өчен, Хөрмәкәй Нугайбеков, хәрби суд тарафыннан хөкем ителеп, җәзага тартылган.

Нугайбектан таралган нәсел бу заманнарда да үзенең газиз нигезендә яши. Алар үзләренең нәсел тарихларын яхшы хәтерлиләр һәм бу хакта истәлекләрне саклау юлында эшлиләр.

## ИСКӘРМӘЛӘР


1 *Әхмәтҗанов М. И.* Юрматы шәҗәрәсе һәм аның версияләре // Мирас, 2000.— № 11.— Б. 22—29.

2 *Рашид ад-дин.* Джами ат-таварих. Том 1, часть 1.— М.: Изд-во «Наука», 1968.— С. 251.

3 Тарихе шәҗәрә-и төрек. Төрки лисанының Казан мөселманлары лөгате үзрә Габделгаллләм Фәйезхан углының иҗтиһады илә һиҗрәтнең 1308 сәнәсендә язылмышдыр.— Казан: Казан университеты тәбгыханәсе, 1891.— Б. 31.

4 *Данзан Лубсан.* Алтан тобчи («Золотое сказание»).— М.: Изд-во «Наука», 1973.— С. 82—83.

5 Шунда ук.— Б. 102.

6 *Шакарим Кудайберды-улы.* Родословная тюрков, киргизов, казахов и ханских династий.— Алма-Ата: «Жазушы», 1990.— С. 37.

7 *Баскаков Н. А.* Ногайский язык и его диалекты.— М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1940.— С. 141.

8 Шежире. Казактың ру-тайпалык курылысы.— Алма-Ата: Изд-во «Рауан», 1991.— С. 33 — 37.

9 *Султанов Т. И.* Кочевые племена Приаралья в XV—XVII вв. (Вопросы этнической и социальной истории.) — М.: Изд-во «Наука», 1982.— С. 42.

10 Һәзә китабе фасыл дастан нәсле Чыңгыз хан вә һәм Аксак Тимер нәселендән бәйан идәр тарих йиди йөз йылында.— Казан, 1882.— Б. 20.

11 *Әхмәтҗанов М. И.* Азнакай районы буйлап // Маяк. КПССның Азнакай райкомы һәм район советы башкарма комитеты органы.— 1976.— 16 сентябрь; *Әхмәтҗанов М. И.* Археографик экспедиция // Маяк. КПССның Азнакай райкомы һәм район советы башкарма комитеты органы.— 1980.— 31 июль; *Әхмәтҗанов М. И.* Татар шәҗәрәләре // Маяк. КПССның Азнакай райкомы һәм район советы башкарма комитеты органы.— 1980.— 12, 14, 16 август; *Ахметзянов М. И.* Татарские шеджере.— Казань: Татарское книжное издательство, 1991.— С. 51 — 52.

12 *Әхмәтҗанов М.И.* Татар шәҗәрәләре.— Казан, 1995.— Б. 28 — 29.

13 *Ризаэддин бине Фәхретдин.* Асар. 10 җөзьэ.— Оренбург, 1904.— Б. 128 — 129. (*Биби* — Ризаэддин бине Фәхретдиннең якын туганының хатыны була.)

14 Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кулъязмалар Мирасханәсе: 99 кол.— 1 тасвир.— 112, 113 эш берәм.

15 Документы ставки Е. И. Пугачева, повстанческих властей и учреждений. 1773—1774 гг.— М.: Изд-во «Наука», 1975.— С. 489.

16 Документы ставки Е. И. Пугачева... — С. 151, 418.


Барлык эпитафик мәгълүматлар М. И. Әхмәтҗановның шәхси архивындагы язмаларга таянып алынды.

## Й О М Г А К

Әлеге язмаларда Кирәйет кабиләсеннән булган Кирәйет би нәселенең 900 еллык тарихы тасвирланды. XI—XII гасырларда үз дәүләтләре, үз ханнары булып, Кытай империясе белән тиңдәшсез көрәштә танылган кирәйетләр — татар тарихында бай эз калдырган кавем, һәм аларның нәселләре бүген дә татар, казакъ, каракалпак, үзбәк халыкларының вәкилләре булып яши. Кирәйетләр тарихына бәйле бу хезмәт фәкать язма тарихи чыганаклар нигезендә язылып, анда автор фантазиясенә урын бирелмәде.

Җыеп әйткәндә, бер нәселнең тарихында бөтен татар милләтенең узгандагы тормышы гәүдәләнә. Алар нәселеннән меңләгән хезмәт ияләрен күрсәтергә мөмкин булыр иде. Алар — иген үстерүчеләр,

нефть чыгаручылар, төзүчеләр, хәрбиләр, юристлар, промышленность белән идарә итүчеләр һ. б. Шулар рәтеннән «Елховнефть» газ һәм нефть чыгаручы идарәнең җитәкчесе Ардинат Нугайбеков, атаклы табиб Айрат Нугайбеков, Татарстанның Русия Федерациясендәге тулы хокуклы вәкиле Нәзиф Мириханов исемнәрен тәкъдир итәргә мөмкин. Ардинат Нугайбеков Чалпы авылының иске зиратында бабалары каберләре өсләренә куелган ташларны яңарту һәм аларны саклау буенча чаралар күреп, кайгыртып йөри. Тымытык авылында корыла торган зур яңа мәчетнең төзелешенә аның ярдәме күп тия. Ардинат әфәнде үзенең нәсел тарихына — шәҗәрәсенә кагылышлы мәгълүматларны да берәмтекләп җыя бара. Аның эшчәнлеге мисалында без атаклы Кирәйет һәм Нугайбектан килгән, ил турында кайгыртып яшәү үрнәген күрәбез. Ык буеның татар җирләре үзенең күкрәгендә гасырлар буе тәрбияләп килгән нәселләргә теләктәшлек күрсәтүен дәвам итә.

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш ........................................................................................................................................

**і бүлек**

Кемнәр алар борынгы башкортлар, һәм алар кайларда яшәгән? Иске тарихи язмаларда сакланган хәбәрләр .........................................................................

Искәрмәләр...........................................................................................................................................

**Іі бүлек**

Нугай Урдасы һәм аның кабиләләре составы .............................................................

Кирәйет шәҗәрәләре ............................................................................................................

1 нче кулъязма версия ...........................................................................................

2 нче кулъязма версия ............................................................................................

3 нче кулъязма версия .................................................................................................

4 нче кулъязма версия ...........................................................................................

5 нче кулъязма версия ..............................................................................................

6 нчы кулъязма версия ..............................................................................................

Искәрмәләр ...............................................................................................................................

Йомгак ...........................................................................................................................................

Заказное издание

**Ахметзянов Марсель Ибрагимович**

**ЛЕТОПИСЬ ОДНОГО ЗНАТНОГО РОДА**

*(на татарском языке)*

Редакторы *Н. К. Нотфуллина*
Рәссамы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Л. Г. Зиргизова*
Корректоры *А. М. Дәминова*

Нәшриятка 183 номерлы лицензия 1997 елның 7 апрелендә бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.09.2001.
Форматы 60х84 1/16. Офсет кәгазе. «Карелия» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 2,79 + форз. 0,23 + 0,93.
Нәшер-хисап табагы 1,57 + форз. 0,42 + рәс. 0,84.
Тиражы 1000 д. Заказ Ч-54.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
E-mail: **magarif@mail.ru.**
ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бау40
ман урамы, 19.